| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 3-6/э

«Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 3-14/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2020 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифларны һәм бәяләрне исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Кирәкле тулай керемне озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган электр энергиясен тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә тарифлар исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, 2020 елга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешмаларның кирәкле тулай керемнәренә үзгәрешләр кертү максатларында Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе»

ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә 2018-2022 елларга аерым тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 № 3-14/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 № 3-5/э карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 3-14/э карарына 1 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-6/э карары редакциясендә)

«Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2018 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2018 | 144 270,55 | 106,27 | 1,03229 | 144 270,55 | 110,52 | 1,03654 |
| | | 2019 | 152 085,78 | 110,81 | 1,08699 | 152 085,78 | 118,45 | 1,09463 |
| | | 2020 | 131 956,36 | 118,56 | 0,96553 | 131 956,36 | 118,56 | 0,96553 |
| | | 2021 | 153 425,29 | 122,88 | 1,10765 | 153 425,29 | 127,79 | 1,11257 |
| | | 2022 | 158 753,28 | 127,79 | 1,14677 | 158 753,28 | 132,90 | 1,15188 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 3-14/э карарына 3 нче кушымта (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-6/э карары редакциясендә)

2018-2022 елларга «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыятенең кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2018 | 12 980,89 |
| | | 2019 | 13 684,07 |
| | | 2020 | 11 872,91 |
| | | 2021 | 13 804,59 |
| | | 2022 | 14 283,98 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге